Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

e-mail: sab.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

«25» сентябрь 2018 ел № 27

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль
берәмлеге территориясендә гражданнардан үзара салым
акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум
билгеләү турында

2002нче елның 12нче июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” №67-ФЗ Федераль законның 15 нче маддәсенә, 2003нче елның 6нчы октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 131-ФЗ Федераль законның 22нче һәм 56нчы маддәләре, Татарстан Республикасының 2004нче елның 24нче мартында кабул ителгән “Җирле референдум турында” №23-ЗРТ 18нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлеге Уставының 11нче маддәсенә туры китереп, Саба шәһәр җирлеге Советының 2018нче елның 21нче сентябрендә кабул ителгән “Референдум уздыру инициативасы турында” гы 26нчы номерлы карары, Саба шәһәр башкарма комитетының 2018нче елның 24нче сентябрендә кабул ителгән “Референдум уздыру инициативасы турында”гы 120нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә автомобильләр һәм җәяүлеләр күперләрен төзәтү (төзү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә һәйкәлләрне төзәтү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең урам юлларын вак таш белән түшәү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә балалар мәйданчыгы төзү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзәтү (төзү);

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов